# Фикер алышыр мәсьәләләр күп



Узган атнада районда Борай башкортлары корылтае үтте. Аның эшендә муниципаль Борай районы башкортлары корылтае башкарма комитеты рәисе Илгиз Харисов, район хакимияте башлыгының инвестицияләр, эшкуарлык һәм икътисад буенча урынбасары Марат Ахунов, Башкортстан Республикасының үзйөрешле машиналар һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек буенча Дәүләт инспекциясе начальнигы Урал Искәндәров, Бөтендөнья башкортлары корылтаеның территорияләр белән эшләү бүлеге начальнигы Гөлназ Сөярголова, район башкортлары корылтае башкарма комитеты әгъзалары, авыл биләмәләре вәкилләре, мәгариф, мәдәният учреждениеләре делегатлары катнашты.

Муниципаль Борай районы башкортлары корылтае башкарма комитеты рәисе Илгиз Харисов корылтайның башкарма комитетының соңгы бишьеллыктагы эшчәнлегенә отчет белән чыкты.

– Үткән V Бөтендөнья Корылтае безнең районда да уңай үзгәрешләргә этәргеч бирде. Милли сәясәт буенча байтак эшләр алып барылды, чираттагы практик мәсьәләләрне кую һәм чишү өчен яхшы әзерлек булдырылды. Шулай ук «Борай районы муниципаль районында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» муниципаль программасы чикләрендә күптөрле тематик чаралар уздырыла һәм планлаштырыла.

Корылтайның башкарма комитеты район хакимияте, мәгариф бүлеге, спорт, мәдәният һәм яшьләр сәясәте идарәлеге, «Алга», «Йәнтөйәк» гәзитләре белән тыгыз бәйләнештә эшли һәм алар белән берлектә районның милли-мәдәни торышын чишәргә ярдәм итә.

Башлангыч оешма буларак, район корылтае әгъзалары районда үткәрелгән бөтен төр чараларда актив катнаша. Исполкомның эш чорында бу эшләр төрле формада үткәрелә: конкурслар, очрашулар, тематик кичәләр.

Республикада кабул ителгән "Башкортстан республикасындагы телләр турындагы закон"ны гамәлгә ашыру максатыннан корылтай әгъзалары районда шушы законны үтәү йөзеннән үткәрелгән бөтен чараларда актив катнашалар. Шушы законның үтәлешен тикшерү максатыннан район оешмаларында башкорт телендә язылган алтакталарны тикшереп рейдлар үткәрәләр, киңәшләр бирәләр. Тарихи язмаларның, географик атамаларның, хуҗалык исемнәренең дөрес язылышы район буенча тикшерелә.

Районда яшәгән халыкның милли составы 2020 елгы халык санын алу мәгълүматлары буенча төзелгән. 2018 ел азагында районда 21892 кеше яшәп, шуларның 70,2 % – башкорт, 21,5 % – татар, 3,7 % удмурт, 2,3 % – рус, 1,6% мари, 0,6 % – башка милләт вәкилләреннән.

Башкортстан Республикасы Хөкүмәтенең "Халык бәйрәме «Шәҗәрә бәйрәме»н уздыру турында»гы карарын тормышка ашыру чикләрендә 2006 елдан башлап һәр авыл советы авыл биләмәсендә, мәдәният учакларында, белем бирү учреждениеләрендә «Шәҗәрә бәйрәме» үткәрелә.

Корылтайның башкарма комитеты милли мәдәниятне, йолаларны тергезү, саклау, туган башкорт телен өйрәнү буенча зур эш алып барган мәдәният учреждениеләре белән тыгыз бәйләнештә тора.

Шулай ук башкорт халкының мәдәниятен пропагандалау максатыннан районда ел саен милли фольклор коллективлары, башкорт халкының мәдәнияте көннәре, халык иҗаты фестивальләре үтә.

2014 елдан Борай җирендә 3 «Таныпсу» дип аталган Бөтенрусия Этно-арт симпозиумы үтте һәм безнең районның бренд чарасына әверелде. «ТаныпСу» арт-галереясе фонды елдан-ел Бөтенрусия Этно-арт симпозиумында катнашучыларның уникаль эшләре һәм әсәрләре белән тулылана. Шушы биш елда «Танып-су» галереясендә үзешмәкәр рәссамнарның өч бизәүкулланма сәнгате күргәзмәсе оештырылды һәм халыкта зур кызыксыну уятты.

Китапханә туган якны өйрәнү фонды халык арасында тарихи-туган як буенча белем һәм мәгълүмат таратуда зур роль уйный. Башкорт әдәбиятының фонды ел саен яхшыра. Соңгы елларда укучылар Мостай Кәрим, Зәйнәп Биишева, Нажар Нәҗми, Әнгам Атнабаев, Айгиз Баймөхәмәтов җыентыкларын яратып укыйлар. Башкортстан Республикасының гражданнар җәмгыятенә булышлык итү фонды ярдәмендә «Җанлы китап: геройлар вакыты» проекты буенча эшләнгән «Вафа һәм Даян», «Салават» «Абдул-Азиз һәм Кәрим: геройлар вакыты», «Без бергә» комиксларына презентацияләр оештырып үткәрелде һәм бик зур кызыксыну тудырды.

Китапханә башкорт телендә түбәндәге басмаларны алдыра: «Башҡортостан», «Йәшлек», «Йәншишмә», «Аҡбуҙат», «Аманат», «Ватандаш», «Башҡортостан уҡытыусыһы», «Башҡортостан ҡыҙы», «Тамаша», «Шоңҡар», «Ағиҙел».

Патриотик тәрбия – күпкырлы мәсьәлә. Ул туган ягыңа сөю, аның тарихын һәм мәдәниятен өйрәнүдән башлана. Шуңа күрә яшь буын белән эшләп, мәдәният һәм мәгариф учреждениеләре белем таратуга зур игътибар бүлә. Моңа тематик кичәләр, әңгәмәләр, китап күргәзмәсе һәм башка чаралар этәргеч булып тора. Мәсәлән, «Башкорт җире кайдан башланган...», «Туган ягым – Башкортстан», «Башкортстанның данлы уллары һәм кызлары – Бөек Ватан сугышы геройлары». Заманның актуаль проблемаларын күтәреп чыккан чаралар бик тере үтә.

Президент мәдәни башлангычлар фонды ярдәмендә районда берничә зур чара үтте. 2022 елда «Танып-Су» II Бөтенрусия Этно-арт симпозиумы, 2023 елда «Җитеннән күлмәккә кадәр» белем бирү-укыту проекты, Хәмдүнә Тимергалиева истәлегенә арналган халык җырларын башкаручыларның төбәкара конкурсы «Кулъяулыгым төшеп калды Борай болыннарында», 2024 елда зур патриотик проект Украинада махсус хәрби операция барышында һәлак булган Батырлык ордены һәм генерал Миңнегали Шәйморатов ордены белән бүләкләнгән Вадим Заһиров истәлегенә арналган «Бердәмлек ритмында» кашыкчылар ансамбльләре фестивале дип аталган проектлар бик күп катнашучыны җәлеп итте.

Районыбызда Тазлар, Ялдәк ырулары җыеннары үтте. Борай делегациясе шулай ук Дүртөйле, Караидел, Миякә районнарында узган ырулар җыеннарында катнашты.

Ел саен башкорт теле буенча халыкара диктант, этнографик диктант уза.

Җиңүләр дә бар. 2020 Башкорт теле елы чикләрендә республикабызның район хакимиятләре һәм урындагы башкорт корылтайлары арасында үткән төп бәйгедә Борай районы 3 урынга лаек булды. 2021 елда Башкортстан тарихы елында Борай районы 1 урынны яулады.

Районыбызның авыл җирлекләре инде берничә ел «Аек авыл» республика конкурсында уңышлы катнаша. Конкурсның район этабында җиңүчеләре Түгәрәк, Алтыбай, Алтаю, Иске Карагыш авыллары республика конкурсының дипломнары һәм призлары белән бүләкләнделәр.

Йомгаклап шуны әйтергә кирәк, безнең районда башкортлар, урыслар, татарлар, удмуртлар, марилар тату яшиләр. Бөтен үткәрелгән чаралар халыкның мәдәни аралашуын һәм милләтара дуслыкны ныгытуга юнәлтелгән, – дип бәян итте Илгиз Зөфәр улы.

Район мәгариф бүлегенең туган телләрне укыту буенча методисты Рәмилә Солтанова районда туган телләрне укыту торышы белән таныштырды.

2024 ел Бөтендөнья башкорт корылтае тарафыннан Яшьләр елы буларак үтә. Район хакимиятенең яшьләр сәясәте буенча сектор мөдире вазыйфаларын башкаручы Лилия Әгъзамова районда яшьләрнең корылтай эшендәге эшчәнлеген бәян итте.

Муниципаль Борай районы башкортлары корылтаеның киләсе бишьеллыкка башкарма комитеты рәисе итеп бертавыштан Илгиз Зөфәр улы Харисов сайланды. Шулай ук башкарма комитеты әгъзалары сайланып куелды һәм Бөтендөнья башкортлары корылтаеның алтынчы съездына делегатлар билгеләнде.

Ахырда корылтайның 11 пунктан торган резолюциясе кабул ителде һәм муниципаль Борай районы башкортлары корылтае эшчәнлегендә актив катнашкан кешеләргә бүләкләр тапшырылды.

**Венера АРСЛАНОВА.**

**Эльвина РАЯНОВА фотосы.**